**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**2026 елны Татарстан Республикасында Хәрби батырлык һәм хезмәт фидакарьлеге елы дип игълан итү турында**

Тарихи хәтерне саклау, гражданнарның бердәмлеген ныгыту һәм барлык буын Ватанны саклаучылар һәм тыл хезмәтчәннәренә ихтирам йөзеннән **карар бирәм:**

1. 2026 елны Татарстан Республикасында Хәрби батырлык һәм хезмәт фидакарьлеге елы дип игълан итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

бер ай вакыт эчендә Татарстан Республикасында Хәрби батырлык һәм хезмәт фидакарьлеге елын уздыру буенча оештыру комитеты төзергә һәм аның составын расларга;

өч ай вакыт эчендә Татарстан Республикасында Хәрби батырлык һәм хезмәт фидакарьлеге елын уздыруның төп чаралар планын эшләргә һәм расларга.

3. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына муниципаль берәмлекләр территорияләрендә Хәрби батырлык һәм хезмәт фидакарьлеге елы кысаларында чаралар уздыру эшен оештыруны тәкъдим итәргә.

4. Федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, җәмәгать берләшмәләренә һәм оешмаларга Татарстан Республикасында Хәрби батырлык һәм хезмәт фидакарьлеге елын әзерләүдә һәм уздыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

5. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Татарстан Республикасында Хәрби батырлык һәм хезмәт фидакарьлеге елын уздыруны киң яктыртуны тәэмин итәргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2025 ел, 17 октябрь
№ 863